ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО ТАРИФАМ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ТАРИФЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ**

07.12.2021

Казан ш.

**КАРАР**

№ 457-97/тэ-2021

«Казэнерго» акционерлык җәмгыяте тарафыннан җылылык белән тәэмин итүче, җылылык энергиясе сарыфларын компенсацияләү максаты белән җылылык энергиясе сатып алучы җылылык челтәрләре оешмаларына җиткерелә торган җылылык энергиясенә (егәрлегенә) Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының 18.12.2018 № 5-96/тэ карары белән билгеләнгән озак сроклы тарифларга 2022 ел өчен үзгәрешләр кертү хакында

«Җылылык белән тәэмин итү турында» 2010 елның 27 июлендәге 190-ФЗ номерлы федераль закон, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Җылылык белән тәэмин итү өлкәсендә бәя хасил итү турында» 2012 елның 22 октябрендәге 1075 номерлы карары, Федераль тарифлар хезмәтенең «Җылылык белән тәэмин итү өлкәсендә җайга салынулы бәяләр (тарифлар) хисаплау буенча методик күрсәтмәләр раслау турында» 2013 елның 13 июнендәге 760-э номерлы боерыгы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 елның 15 июнендәге 468 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасының Тарифлар буенча дәүләт комитеты турында нигезләмәгә нигезләнеп, «Казэнерго» акционерлык җәмгыяте тарафыннан җылылык белән тәэмин итүче, җылылык энергиясе сарыфларын компенсацияләү максаты белән җылылык энергиясе (егәрлеге) сатып алучы җылылык челтәрләре оешмаларына җиткерелә торган җылылык энергиясенә (егәрлегенә) 2022-2023 елларга озак сроклы тарифларны үзгәртү максатларында, җайга салынулы оешманың план буенча 2022-2023 елларга кирәкле тулай керемнәрен тәгаенләштереп, Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының «Казэнерго» акционерлык җәмгыяте тарафыннан җылылык белән тәэмин итүче,

җылылык энергиясе сарыфларын компенсацияләү максаты белән җылылык энергиясе сатып алучы җылылык челтәрләре оешмаларына җиткерелә торган җылылык энергиясенә (егәрлегенә) 2019-2023 елларга тарифлар билгеләү турында» 18.12.2018 №5-96/тэ карары (Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының 11.12.2019 №5-103/тэ, 16.12.2020 №452-88/тэ-2020 карарлары нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) кушымтасына, аны яңа редакциядә биреп (кушымтада бирелә), үзгәреш кертергә.

2. Бу карар рәсми басылып чыккан көненнән башлап 10 көн узгач үз көченә керә.

Рәис А.С.Груничев

Татарстан Республикасы Тарифлар
буенча дәүләт комитетының
18.12.2018 № 5-96/тэ карарына кушымта
(Татарстан Республикасы Тарифлар
буенча дәүләт комитетының
07.12.2021 № 457-97/тэ-2021 карары
редакциясендә)

«Казэнерго» акционерлык җәмгыятеннән җылылык белән тәэмин итүче оешмаларга, җылылык энергиясен югалтуларны компенсацияләү максатында җылылык энергиясен сатып алучы җылылык челтәрләре оешмаларына җиткерелә торган җылылык энергиясенә (егәрлегенә) 2019-2023 елларга календарь буенча бүленгән тарифлар

| Т/с | Муниципаль берәмлек, җайга салынулы оешма атамасы, тариф төре | Ел | су | Басым астында сайланган пар | | | | Әче һәм редукцияләнгән пар |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | 1,2 башлап 2,5 кг/см$^2$ кадәр | 2,5 башлап 7,0 кг/см$^2$ кадәр | 7,0 башлап 13,0 кг/см$^2$ кадәр | 13,0 кг/см$^2$ югары | |
| | Казан шәһәре | | | | | | | |
| 1 | «Казэнерго» акционерлык җәмгыяте | | | | | | | |
| | бер ставкалы, сум/Гкал | 01.01.2019 башлап 30.06.2019 кадәр | 1190,25 | - | - | - | - | - |
| | | 01.07.2019 башлап 31.12.2019 кадәр | 1213,44 | - | - | - | - | - |
| | | 01.01.2020 башлап 30.06.2020 кадәр | 1213,44 | - | - | - | - | - |
| | | 01.07.2020 башлап 31.12.2020 кадәр | 1251,76 | - | - | - | - | - |
| | | 01.01.2021 башлап 30.06.2021 кадәр | 1251,76 | - | - | - | - | - |
| | | 01.07.2021 башлап 31.12.2021 кадәр | 1273,88 | - | - | - | - | - |
| | | 01.01.2022 башлап 30.06.2022 кадәр | 1273,88 | - | - | - | - | - |
| | | 01.07.2022 башлап 31.12.2022 кадәр | 1330,59 | - | - | - | - | - |
| | | 01.01.2023 башлап 30.06.2023 кадәр | 1330,59 | - | - | - | - | - |
| | | 01.07.2023 башлап 31.12.2023 кадәр | 1384,43 | - | - | - | - | - |

Татарстан Республикасы Тарифлар
буенча дәүләт комитетының тариф
чишелешләрен кабул итүне оештыру,
контрольдә тоту һәм теркәү бүлеге